ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ * 2020 * КАЗАН

5



Валерий ТАРАСЕНКО

Хәмид ВӘЛИДИ

ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ КӨНЕНДӘ ЯЗЫЛГАН ХАТ

"Беркем онытылмады,
Истә һәрнәрсә"
(О. Бергольц)

Саубуллашып китеп барганыңа
Үтте, әти, бик күп, бик күп ел.
Синсез бәйрәм бәйрәм түгел, әти,
Безнең күңел тулы сагыш-моң.

Билгелибез бәйрәм итеп кенә,
Шуңа күрә "бәйрәм көне"н без.
Бәйрәмнәрнең син китканнән бирле,
Ямен-тәмен без бит белмибез.

Илне саклап, гомерең киселсә дә,
Ә ил безне санга сукмады.
Бер сәбәпсез яңаклады безне,
Бер дә юкка тотып тукмады.

Ана телсез кала яздык илдә,
Парламентка үтеп керә алмый.
Түрә-кортмән, никтер, җирәнә дә,
Дошманыдай аны күрә алмый.

Билгелибез җитмеш биш еллыгын…
Искә алучы безне булмады.
Фронтовиклар гаиләсен кочып,
Син утырткан таллар елады.

Әни көтте. Көтеп аламады,
Ишелеп бара син бураган йорт.
Шуны белдек: әти-әтисезләр –
Гомер буе гел икенче сорт.

Исән булсаң, булыр идек без дә
Яңа салган йорттан фатирлы.
Агызыр идек язгы ташкыннарда
Иңне баскан хәсрәт, моң-зарны.

Ел саен без билгелибез генә,
Чын бәйрәм бит бездән еракта.
Түрәләрдән сорапып алып булмый, –
"Сезнең фатир, – диләр, – зиратта".

Һәр яз саен "Җиңү көне" безгә
Кагып китә сугыш сөремен.
Бик уфтанма, – диеп, юата тик
Ишегалдындагы ак сирень.

Хатны яздым, әмма салмыйм, әти, –
Белгертәсем килми бу хәлне.
Бик буталды илдә ак вә кара, –
Хәрәм таптый бүген Хәләлне.

Ринат АБЗАЛОВ



Константин ЧАХИРОВ

АДАШКАН ФИКЕРЛӘР

- Бөтен яңа нәрсә – аңлап җиткерелмәгән иске әйбер.
- **Үзең ышанмасаң – башканы ышандырырга тырышма.**
- Ахыр заман җиткәч, безнең өчен дә яхшы заманнар килер әле!
- **Намус аны күптән борчымый иде: ул борчый-борчый хәлдән тайган иде.**
- Алар никахта бәхетле иделәр: хатын – бәхетле, ә ир – никахта.
- **Кеше бөтен сөйләнгән нәрсәгә дә ышанып бетә алмый, ә башкаларга аны бик җиңел тапшыра ала.**

ШОМБАЙ *болай диде…*



Хөрмәтле редакция! Сезнең «Чаян»да миңа аеруча чит планета кунаклары турындагы карикатуралар ошый. Әйтергә кирәк бу тема белән мин күптәннән кызыксынам. Галимнәр аларның Җирдә булу-булмаулары турында дистәләгән еллар буе бәхәсләшәләр. Миңа калса, ерак планеталарның затлары кайчандыр бездә булып киткәннәрдер дип уйлыйм…

Т. ГАЙСИН

ТҮБӘН КАМА

– Ә нигә кайчандыр? – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Җирдә алар бүген дә җитәрлек. Безнең хакимнәребез, мәсәлән, күптәннән башка планетада яшиләр.**

Ринат АБЗАЛОВ

КАЙЧАГЫНДА ИСКӘ АЛЫГЫЗ...

Күпме еллар инде карт тупыллар
Минсез коя ап-ак мамыгын.
Ничәнче ел уйчан өрәңгеләр
Шыбырдаша, сөйләп сагынуын.
Бөдрә таллар елга көзгесенә
Карый-карый, мине көтәдер;
Кайтты микән, диеп тургайлар да
Кыр өстеннән очып үтәдер...

Көтмәгез сез...
Өй артында миләш,
Мине сагынып юкка елама.
Жиргә иңгән иске туган йортым,
Моңсуланып мине уйлама.

Көлде язмыш...
Берлин урамында,
Май аеның ямьле көнендә
Дошман көпшәсеннән соңгы пуля
Дучар итте мине үлемгә.
Ул үлемне сугыш кырларында
Адым саен янда күрдем мин.
Ут-күмерле канлы ул юлларны
Курыкмыйча атлап үттем мин...

Белмим, хәзер нинди ир-егетләр
Минем сукмакларны таптыйдыр?
Аның өчен гомерем биргән илем
Кая таба бүген атлыйдыр?..

...Тыныч булыр йокым, мин яклаган
Ил-ватанга тугры калсагыз,
Һәм шул илнең гади бер солдатын
Кайчагында искә алсагыз...



Пенсионерка Гафифә түтәй депутаттан килгән ярдәм пакетын бушатты. Һәм гаҗәпсенеп андагы әйберләрне карый башлады. Кызыл һәм кара икра, ысланган колбаса, затлы балык, киптерелгән диңгез кысласы, коньяк, виски...

Шул ук вакытта депутат хатыны, исе китеп, кичке ашка ире алып кайткан пакеттагы әйберләрне барлый иде. Бер кап шикәр, үсемлек мае, тары ярмасы һәм бер банка кильки балыгы...

Нишлисең бит, барыбызның да ялгышуы мөмкин...





Бөтен ил үзизоляция дигән сәер халәткә чумган чакта, мошенниклар һәм ялганчылар үзләрен карантин белән чикләргә ашыкмадылар. Пандемия алар өчен яңа мөмкинлекләр ачты. Һәм галимнәр коронавирустан котылу чарасын уйлап чыгару өстендә баш ватканда, шома аферистлар куркудан югалып калган халыкны алдауның яңа ысулларын таптылар. Шәһәр-авыллар, фатирлар һәм йортлар буйлап ялган табиблар, волонтёрлар һәм социаль хезмәткәрләр сәфәр чыкты. Интернетны тылсымлы аппаратлар, яман кизүдән могҗизалы дарулар басып алды. Ә кибетләрдә коточкыч бәяләр буенча аптекалардан күчеп утырган маскалар һәм антисептиклар урын алды...

"Беренче карлыгачлар" булып үзизоляция режимын бозу турында СМСлар очып килгән. Жуликлар, казанлыларны җинаять эше кузгату белән куркытып, бер тәүлек эчендә 4 мең сум күләмендә штраф түләү таләп итә башлаганнар. Акчаны... Красноярск краенда теркәлгән телефон номерына җибәрергә кирәк булган.

Алдауның иң ышанычлы ысулы булып, әлбәттә, телефоннан шалтырату калды. Менә Казанда да билгесез бәндәләр, аптекалар белән элемтәгә кереп, җитәкчелек исеменнән, имеш, әле генә килгән маскалар һәм антисептиклар өчен акча күчерүне таләп иткәннәр. Бу кармакка мошенникларга 87 мең сум күчергән яшь аптека хезмәткәре капкан...

Маскалар турында берничә сүз. Пандемия башлану белән алар кинәт кенә юкка чыкты, казанлылар югалып калды. Шома жуликлар шуннан да табыш алырга булган. Шәһәрнең сәүдә челтәрендә ике сумлык маскалар җитмеш сумга сатыла башлагач, казанлылар таң калды. Тиздән алыпсатарларның берсен кулыннан тоталар. 35 яшьлек Рамил Н. Интернет аша маскаларны берсен 44,5 сумга "төртеп" яткан булып чыга. Аның фатирында 52 мең маска һәм ярты миллион акча табыла. Ә бу инде законсыз эшмәкәрлек һәм теркәлмәгән медицина чаралары белән сәүдә итү статьясына туры килә.

Җиңел акча сөюче берәү маскалар сатып, һавадан акча ясаган арада, икенчесе зур күләмдә ялган антисептик әзерләп яткан. Хокук саклчылары Казанда яшерен цех тапканнар. Анда эшчеләр эшләгән, ә складында тонналаган әзер продукция сакланган. "Антисептик" җитештерүне 33 яшьлек Денис Д. оештырган. Хәзер үзешчән "фармацевт"ны суд органнары белән очрашу көтә.

Спекуляция белән ялган товарлар җитештерү – дөньяның үзе кебек, иске нәрсә. Ләкин кеше алдап акча ясау өлкәсе дә яңа технологиялардән артта калырга теләми. Күптән түгел Интернет аша яңа компьютер вирусы җибәрелгән. Аны эләктергән смартфоннарда Coronavirus дип аталган бит барлыкка килә һәм янәшәдә әлеге авыру белән зарарланган кешеләр булуы турында хәбәр бирә. Ә ул кешенең кайда икәнен төгәл белү өчен 60 сум түләргә кирәк. Бу гамәлдән соң караклар үзләренә кирәк нәрсәгә – беркатлы гражданнарның банк карталары мәгълүматларына ия булалар...

Вакыт узар, һәм коронавирус исемле дөньякүләм акылдан язу тынар. Бөтен Җирне тетрәтеп торткан кизү юкка чыгар. Тормыш үз юлына кайтыр. Ләкин башкаларны алдап көн күрүче кабахәтләр беркая да китмәс – алар вирустан яшәүчәнрәк, аларны вакцина белән генә бетереп булмый. Һәм бу яман авыруны тиз генә җиңеп булмас, ахрысы...

Илгиз ИСКӘНДӘРЕВ









• • •

– Мин кичә лотереяга бер миллион оттым!

– Хатының шаккаткандыр инде?

– Әйе, шатлыгыннан телен йотты – ни әйтергә белми.

– Карале – берьюлы нихәтле бәхет!

• • •

Ниһаять шундый вакытлар җитте – спирт исе кешеләрдә өмет һәм хөрмәт уятты!

• • •

Барыбыз да кулларны дөрес юарга өйрәндек. Киләсе пандемиянең темасы – муенны юу.

• • •

– Климат үзгәрүгә иң төп сәбәпче – кешеләр.

– Монда миңа юк-бар сөйләп утырмагыз! Син әйт: кайчан, ниһаять, батареяларда җылы бирүне туктатасыз?!

• • •

– Әлү! Телевидениеме? Бу – "Авылга арт белән" тапшыруымы?

– Юк, бу – "Шәһәргә йөз белән" тапшыруы!

– Ә авылга ник алай?

• • •

Банкка балалар бакчасы өчен түләргә кергән идем, паспорт сорадылар. Ни өчен паспорт кирәк, дигән соравыма, керемнәрне җинаять юлы белән үзләштерүгә каршы көрәшү максатында ачыклау һәм террорчы оешмалары финанслауны булдырмау өчен эшләнә, диделәр. Һәрвакыт уйлап йөри идем шул: безнең әлеге бакчада нәрсәдер мәташтерәләр, дип.

• • •

Бер пар оекбаш – ул сезгә аккошлар түгел, алар үлгәнчегә кадәр бергә яши алмый...

• • •

Рәсәйдәге кышның быел шактый җылы булу сәбәпле, җылыткыч өчен түләүләр буенча мин спонсор булдым.

• • •

Язмыш безне диваннарга ташлады.

САТИРА УТЫ БЕЛӘН

«Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» – Бөек Ватан сугышы елларында бу сүзләр совет халкының тормыш шигаре булды. Рәссамнар да үзләрен алгы сызыкта итеп тойдылар һәм дошманга каршы канлы көрәштә үзләренең иҗатлары белән халыкка хезмәт итүне бурычлары итеп куйдылар. Сугыш вакыйгаларын беренче булып яктырта башлаучылар плакатчы рәссамнар һәм карикатурачылар иде. Сугыш башлануның икенче көнендә үк Кукрыникслар ясаган "Дошманны рәхимсез тар-мар итик!" плакаты барлыкка килде.

Беренче атналарда дошманны мыскыллы рәвештә сурәтләүгә каршы тавышлар яңгырый башлады. Имеш, бу җилбәзәклек халык өчен зыянлы. Җәмгыятьтәге хәл бары тик усал, кырыс, фашистлардан үч алуга һәм аларны юк итәргә өндәүче образлар гына таләп итә. Ә сугыштан көлке ясау урынлы түгел.

Ләкин совет сатирасы бу юл белән китми. Дошманнан курыккан кеше генә аннан көлми бит. Әлбәттә, тәнкыйтьчеләр тәкъдим иткән юнәлеш тә кирәк булган һәм ул үзенең агитация ролен уйнаган, әмма көлкедән бөтенләй баш тарту дөрес булмас иде…

Ул вакытта Казанда Бауман урамында урнашкан Татар дәүләт нәшрияты сугышның беренче көннәреннән үк фашистларга каршы плакатлар чыгара башлый. Аларның авторлары Б. М. Альменов, Р. Ф. Сәйфуллин, Н. М. Сокольский, А. М. Родионов һәм башка рәссамнар була. Бер ел эчендә генә Татгосиздат рус һәм татар телләрендә ярты миллионнан артык плакат бастырып чыгара.

Типография ысулы белән эшләнгән плакатлардан башка, Казанда кул белән башкарыла торган трафарет техникасында 170 сан "Сатира тәрәзәсе" әзерләнә. Аның өстендә чаянчылар И. Е. Бобровицкий, Э. Б. Гельмс һәм шагыйрь Б. Зернит эшли. Эш шартлары бик авыр була. Кәгазь җитми. Салкын булу аркасында өске кием һәм киез итекләр киеп эшләргә туры килә. Ләкин ярым ач рәссамнар авырлыкларга бирешмиләр. "Сатира тәрәзәләре" даими рәвештә, вакыйгаларны көнендә үк яктыртып, аена 4 тапкыр 300 экземпляр күләмендә чыгып килә. Аларны шәһәрнең халык тупланган урыннарында урнаштыралар. Сугыш елларында барлыгы йөз җитмеш чамасы "Сатира тәрәзәләре" чыгарыла. Рәссамнар иҗатлары белән кешеләрнең уй-тойгыларына тәэсир ясап, Җиңүгә үз өлешләрен кертәләр.







Солдат көлә, елмая...

Бөек Ватан сугышында күп кенә хәрби татар газеталарында "Чаян – фронтта" дигән почмаклар оештырыла.

Шул газеталардан берничә мәзәк һәм карикатура урнаштырабыз.

ХУҖА ҺӘМ ГЕНЕРАЛ

Көннәрнең берендә фашистлар Хуҗаны тотып алганнар да кыйный-кыйный генерал янына китергәннәр. Гитлер генералы аждаһа кебек дулаган, елан кебек сызгырган да:

– Минем сорауларыма дөрес җавап бирмәсәң, астырам. Йә, әйт, дөньяда иң кызу җир кайда? – дигән.

– Нимечләр өчен Сталинград янында, – дигән Хуҗа.

– Иң салкын җир? – дип җикеренгән генерал.

– Төньяк Африкада, – дигән Хуҗа.

– Асам мин сине, хәзер үк асам, – дип ачуланган да. – Дөньяда иң каты йөгерүче нинди хайван бар? – дип сораган генерал.

– Төньяк Африкада пәйда булган Роммель исемле җанвар, – дип җавап биргән Хуҗа.

Генерал, төкерекләрен чәчеп:

– Дөньяда ничә алдакчы бар? – дип кычкырган.

– Өч, – дигән Хуҗа.

– Кемнәр алар?

– Берсе – Иблис, икенчесе – Геббельс, өченчесе – Гитлер, – дигән Хуҗа.

– Үтерәм, хәзер үк асам мин сине, – дип, Хуҗага ташланган генерал.

Әмма генералга кулларын күтәрергә туры килгән – штабка партизаннар бәреп кергән.

"Фронт правдасы", 1943 ел.



ХУҖА – ДОКТОР

Хуҗа доктор булып немецлар арасында йөри икән. Бер фриц Хуҗа янына килеп:

– Йә, доктор әфәнде, ни эшлим, башымның авыртуына чыдап булмый, – дип зарланган.

Хуҗа – аңа:

– Бүгенгә чыда, иртәгә бетәр, – дигән.

– Шулаймы, авыруым бетәрме? – дип сораган фриц.

– Әйе, авыруың бетмәсә, башың бетәр, – дигән Хуҗа.

"Алга, дошман өстенә", 1944 ел.

ИНТЕРВЬЮ

Бервакыт Хуҗадан кызылармеецлар:

– Йә, Хуҗа, әйт әле, немецлар бигрәк тә нәрсәне яратмыйлар? – дип сораганнар.

– Казанны, – дигән Хуҗа. – Чөнки, безнең кызган казанга төшеп, Гитлерның уннарча дивизиясе кайнап парга әйләнде.

– Тагын?

– Тагын чалбарны яратмыйлар. Бездән качкан вакытта йөгерергә мишәйт кенә итә, – дигән Хуҗа.

"Алга, дошман өстенә", 1944 ел.

ДОН БУЕНДА САБАНТУЙДА

Герман һәм итальян гаскәрләре өчен Кызыл Армия Дон буенда зур Сабантуй уздыра. Сабантуй безнең артиллерия музыкасы һәм пулеметлар җыры астында бара. Немецлар һәм итальяннар күрсәткән кайбер кызык номерлар белән таныштырып үтәбез.

Сабантуй биеклеккә сикерү белән башланды. Мондый сикерешнең немецлар өчен файдасы бик тә зур: алар, киредән җиргә төшеп тормыйча, турыдан-туры "теге дөньяга" үк олагалар.

Немец танкистларының дөрләп янган танктан сикерү номеры. Монда хикмәт танк эчендәге 4-5 кешенең кайсысы элегрәк сикереп кала алудан тора. Тик моның осталары бик аз чыкты.

...Йөгерештә генераллар беренче урынны алды.

...Солдатларның берсе дә генералларга җиткерә алмады. Аларның бик күбесе җиргә егылды, калганнары, аяк белән эш чыгара алмагач, дәррәү кул күтәрделәр.

ИКЕ ФРИЦ КИҢӘШӘ

– Нишләргә инде, руслар бигрәк нык аталар, башны күтәрер хәл юк.

– Башны күтәрмичә үкчәләрне генә күтәрсәк яхшырак булмасмы?



АТАКАДАН СОҢ

– Миңа бик тиз обер-лейтенант Людвигны табарга кирәк.

– Нигә, әллә берәр ашыгыч приказ бармы?

– Юк, гәүдәсен табып кумәргә куштылар.

"Совет сугышчысы", 1944 ел.





Бөек Җиңүгә – 75 ел!

КАРАНТИНЛЫ КАРТЛЫК

Милләттәшләребез арасында миһербанлы кешеләр һәрчак булган һәм бүген дә бар. Заманчалап волонтерлар дип әйтсәк тә була аларны. Дәүләт органнары оештырып биргәннәреннән аермалы буларак, авылларда үзләре белгән кешеләрне үз хисапларына шефлыкка алучылар да бар. Бу арада тирәякта карантин хөкем сөргәндә алар аеруча тирән мәгънәгә ия. Ачык интернет чыганаклары белән танышып утырганда таныш кешеләр төшерелгән видеоролик күземә чалынды. Бу турыда бераз тәфсилләбрәк язарга булдым.

Тыл ветераны Минсылу апа Мөхәммәтгалиевага 94 яшь. Сугыш башланганда аңа 15 яшь булган. Гомер буе ул Тымытыкта ашханә, урта мәктәп һ. б. оешмаларда җыештыручы була, колхозда төрле эшләрдә эшли. Андыйларга пенсияне ару түлиләр дигән сүз йөри, әмма бу дөрес түгел, әби 13 мең сум ала. Ремонт күрмәгән иске өе кышларын өстендәге бишмәтен салып йокларлык булмый, диләр авылдашлары. Кемнәрдер, сугыш чоры михнәтләрен үз җилкәләрендә татучылар буларак, торак шартларын яхшырта алды бит. Нишләп бу программа Минсылу әбине читләтеп үтте икән?

Ялгызы яшәп картайган ул. Тымытыкта бик күп буш торган таш биналарга йозак эленгән. Әле соңгы елларда гына кирпечтән төзелгән бер катлы менә дигән хастаханә бинасын сүттеләр. Аның төзелү вакыты да минем күз алдында, 1970 нче еллар уртасында гына иде бит әле. Кирәксез булгач, аны Ветераннар йорты итеп җиһазлап, Минсылу апа кебек 10 ялгыз кешегә менә дигән тулай торак ясап бирәсе иде. Юк, алай итсәң кешечә була бит. Тымытык үзәгендә ике административ бинаның искесе буш диярлек. Минсылу апа күрше-тирәсендә яшәүче миһербанлы кешеләр, ягъни волонтерлар кайгыртуы аркасында Ходай биргән гомерен яшәп ята.

Ленинга – 150 ел, ТАССРга – 100 ел, Бөек Җиңүгә 75 ел тулганда Минсылу әби кебек ярдәмгә мохтаҗ 80-90 яшьлекләр дә бар бит арабызда. Алар гомер буе ил өчен дип бил бөксәләр дә, бу көнгә калырбыз дип башларына да китермәгәннәрдер. Сугыш чоры балалары дип сөйләнүебез дә буш сүзләр генә булып кала бирә. Элеккеге район үзәгендә, урта мәктәбе дә авыл күрке булып торган Тымытыкта яшь буынга нинди үрнәк күрсәтәбез бит, җәмәгать.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,
муниципаль берәмлек депутаты,
хезмәт ветераны,

Борис СТАРЧИКОВ, Бөек Ватан сугышы ветераны
«Чаян» № 4, 1960



– Жалоба кенәгәсен бирегез!

Виктор ИГНАТЬЕВ, Бөек Ватан сугышы ветераны
«Чаян» № 9, 1960



– Башка сыймаслык! Миңа карчык роле тәкъдим итәләр! Соңгы кырык ел эчендә мин яшь кызларны гына уйнарга күнектем!

Гөлнара ГОМӘРОВА

КИЛ, КӨТӘБЕЗ!

Телефоным шалтырады. Таныш булмаганниндидер тавыш ишетелә.

– Мәдинәкәй, сәлам, җанкай!

– Танымадым – баерсың...

– Рәхмәт.

– Ә шулай да... кем соң әле?..

– Танышларыңны оныту яхшы түгел... – дип дәвам итте танымаган кешем. – Бу – Альбина, хәтереңдәме?

"Кем соң әле бу Альбина?" – дип, мин исемдәгеләрне барларга тотындым. Телефон беразга тынып торды.

– Онытмагансыңдыр бит, үткән ел без синең белән Ялта пляжында танышкан идек...

– Әйе битәле...– дигән булдым мин, уңайсызланганымны яшерергә тырышып.

– Мин ул чакта ирем Руслан белән идем... Теге – бизнесмен... Шиномонтажник...

Ниһаять, мин бу вакыйганы тулысынча искә төшердем: пляж, диңгез, кыланчык Альбинаны һәм сыра эчүдән тәпән хәтле бүксәле Русланны.

– Менә сине кунакка чакырасыбыз килә, – дип дәвам итте сүзен пляждагы танышым. – Рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз... Шундагы кызыкларны искә төшерербез... Иртәгә кичкә килә алырсыңмы?

– Әйтә алмыйм шул... – Мин каушабрак киттем. – Эшем күп, бик арылган да...

– Ярар инде... – дигән булды Альбина. – Элеккеге танышлар өчен вакыт тапмаска? Менә минем Русланымның эше муеннан – отчетлар, түләнеп бетмәгән бурычларының очына чыгып бетә алмыйча җафалана, ә синең өчен вакытын сарыф итәргә әзер!

– Алай булса, килермен...

– Менә, бик әйбәт! Көтәбез... Карале, сүз җаеннан бер нәрсә сорыйсым килә, син һаман да район салым оешмасында эшлисеңме?

– Юк, киткәнемә бер ел тула...

– Ничек инде киттең? – дип гаҗәпкә калды ул. – Үзеңме?

– Үзем...

– Алай и-икән, аңлыйм хәлеңне...

– Зарланмыйм, барысы да әйбәт...

Телефонда тынлык барлыкка килде. Ләкин ул озакка сузылмады һәм Альбина яңадан тәтелдәргә тотынды.

– Әй Мәдинәкәй, онытканмын бит! Иртәгә без үзебез кунакка чакырылганбыз икән, гафу ит инде...

– Аптырамагыз, булгалый...

– Димәк, син налоговыйда түгел?

– Нигә алай дисең... Мине шәһәрнекенә күчерделәр...

– Шәһәрнекенә?! Кара инде, Мәдинәкәй, башым бөтенләй буталган, ни...

– Нәрсә ни?..

– Без иртәгә кунакка бармабыз, мөгаен. Синең белән күңеллерәк булыр! Утырырбыз, сөйләшербез, пляжны искә төшерербез... Берочтан синең яңа урынга күтәрелүеңне юарбыз... Кил, кадерлем, өзелеп көтәбез!



Ринат МӘННАН

ПАТША...

Коронавирус Җир шарын
Яулап алырга тели,
Кәнәфидә утырыплар
Патша булырга тели.
Тик коррупция вирусын
Белми әле ул, белми...
Бүгенге көн Патшасы ул –
Аны җиңалмый берни!

СОҢГЫ СУЛЫШЫНА КАДӘР

Сәламәт килеш стаж җыйгач,
Ялга чыкмак булды сыер.
Җибәрмәделәр, әйттеләр:
"Пенсиясез эшләп син йөр!
Яшең зур, ләкин дәртең бар,
Мөмкинсең бозау табарга!
Имчәгең дә – сөбханалла!..
Саусыннар исән чагында!"
Мескенгә дару каптырып,
Өч ел иртә-кич саудылар.
Хәлдән таеп аугач, аны
Үләт базына салдылар...

Ышаныгыз: комсыз карын,
Безне салыр гүргә кырын.

Алмаз ХӘМЗИН
Интернеттагы шигырьдән тәрҗемә.



МИРЗАҺИТ ТОРМЫШЫННАН

Авыл мәзәкчесе Мирзаһит тормышыннан һәни хикәятләрне бастыруны дәвам итәбез. Аның үзе турында сөйләп торуның кирәге юктыр – андый Мирзаһитны теләсә кайсы рус, чуаш, мордва, башкорт авылларында табып була бит.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТЕВ

ИРТӘРӘК ӘЛЕ

Берзаман Мирзаһитка интернет-провайдерның мәгълүмат үзәгеннән шалтыраталар. Йомшак тавышлы яшь кыз пенсионерлар өчен акция уздырылу турында хәбәр итә һәм арзан бәягә телевидение, телефон һәм Интернет тоташтырырга тәкъдим итә.

Мирзаһит сабыр гына кызыйның сайравын тыңлап тора да, ул тын алырга туктаган арада үзенең иске кнопкалы телефон трубкасына әйтеп куя:

– Интернат дисеңме? Картлар өченме? Юк, җанкисәгем, миңа анда иртәрәк әле, хәзергә үз йортымда яшисем килә!

"Интернат" белән Мирзаһитны башка борчымыйлар...

ТӘРБИЯЧЕ

Бер көнне Мирзаһит кибет янында ферма мөдире Миннәхмәт Ризвановичны очрата. Тегесе зарланырга тотына:

– Эшчеләр ялкау, берни дә белмиләр һәм белергә дә теләмиләр. Хатын-кызлар сүз тыңламый, ирләр эчә. Өстәвенә, урлашалар, эштән качып китәләр һәм каршы әйтәләр! Нәрсә өчен бу миңа? Нишлим икән? – дип өзгәләнә мөдир.

– Юкка борчыласың, – ди аңа Мирзаһит, игътибар белән тыңлаганнан соң. – Әгәр алар бөтен нәрсәне дә тиешенчә эшләп торса, синең кирәгең дә булмас иде бит. Шуңа күрә шатланып яшә һәм тәрбия эшләреңне дәвам ит!

ГӨЛҖИМЕШ КУАГЫ

Мирзаһит гауга-җәнҗалларны яратмый һәм һәрчак алардан читтә булырга тырыша иде. Шуңа күрә яз башында хатыны бакчада гөлҗимеш куагы утырткач, ул бер сүз дә әйтмәде. Бу энәле әрсез, бөтен җирне басып ала торган үсемлекне аның җене сөйми иде. Тик хатыны көннәр буе кызыл җимешләрнең файдасы турында тукылдый бирә.

Бер ай үтә, инде сирень чәчәк коя, ә гөлҗимеш үсәргә ашыкмый. Хатыны аптырашка кала: үзе шундый әрсез куак бит югыйсә, ә ул утыртканы үсми!

Беркөнне иртән күршесе Мирзаһитның бичара куакны казып алып, яңадан утыртканын күреп ала. Икенче иртәдә шул ук хәл кабатлана.

– Син нишлисең? – дип сорый гаҗәпләнгән күршесе.

– Гаилә гаугаларына таралырга бирмим! – дип җавап бирә Мирзаһит.

Виктор ФЁДОРОВ
елмая







Абау!

ЮЛ РИШВӘТЧЕЛӘРЕ

Роспотребнадзорның Татарстандагы өч инспекторы *зур йөк машиналары* йөртүчеләрен "саварга" булганнар. М7 трассасында үлчәү контролёрлары, йөк авырлыгы тиешледән артык булган очракта моны теркәп, штраф язарга ашыкмаганнар, ә турыдан-туры акча таләп иткәннәр. Алар сораган 15 мең сум максималь штрафтан кимрәк булганга, машина йөртүчеләрнең күбесе "уртак тел табуга" каршы килмәгән. Әлегә юлда ришвәт алуның 6 очрагы ачыкланган.

КАРА УРМАННАРНЫҢ УРТАСЫНДА

Кукмара районындагы Ошторма-Юмья җирлегенең элекке депутаты белән хокук саклау органнары кызыксына башлаган. Ул җиде ел элек бер файдасызга шаулап утырган урманга игътибар иткән. Депутат авыл кешеләренең төзелеш өчен агач яисә утынга мохтаҗ булулары турында белешмәләр яза башлаган. Бу кәгазьләр буенча урман хуҗалыгы агачны ташлама белән саткан. Тик авылдашлары үз мәнфәгатьләре турында берни белмәгән, ә арзан бәягә алынган бүрәнәләр билгесез юнәлештә китеп торган. Депутат эшчәнлеге нәтиҗәсендә, урман хуҗалыгына 310 мең сумлык зыян килгән.

ТҮЛӘҮЛЕ БЕЛЕШМӘЛӘР

Балтач үзәк хастаханәсенең табиб-психиатры ялган белешмәләр белән әләккән. Ул, тискәре диагнозларга карамыйча, акча өчен автомобиль белән идарә итәргә рөхсәт итүче 124 бәяләмә биргән. Белешмә ясау остасы акчаны үзенең икенче эш урынына – невролог вазыйфаларын үти торган башка медицина оешмасына күчереп барган. Гади бу схеманы тиз ачканнар. Нәтиҗәдә, психиатр берьюлы ике җинаять статьясына дучар булган.

ҮЗ КЕСӘСЕНӘ

Лаеш районының сукырлар мәктәп-интернатында моңа кадәр директор булып эшләгән ханым үзенең матди хәлен яхшыртырга булган. Ул булмаган кешеләрне интернатка эшкә урнаштырып, аларга тиешле хезмәт хакын үзе алып яткан. Аннан башка, мәктәп расписаниесенә үзе өчен өстәмә дәресләр кертеп, алар өчен акча алып барган. Әмма укыту эшләре алып бармаган. Өстәвенә, шома ханым мәктәп өчен хуҗалык товарлары алу турында килешенүләр төзеп, ул максатка кергән акчаны үз кесәсенә шудыртып барган. Элекке җитәкченең рухи сыйфатларына суд бәя бирәчәк.







УЛ!
Чын чаянчы булган икән –
Нигә безгә язмаган?
Әллә тыелып торганмы,
Әллә Ходай язмаган?

Әллә безләр тиң булмаган
Шигъри киң талантына?
Юкса коенып яшәде
Халык яратуына...

Алмаз ХӘМЗИН

ШУНДЫЙ ИЛ ИНДЕ МЕНӘ...

Кычкырасың – ишетмиләр...
Чукраклар иле.

Күрсәтәсең – юк, күрмиләр...
Сукырлар иле.

Сорыйсың – җавап бирмиләр...
Телсезләр иле.

Сыныйсың – дога белмиләр...
Динсезләр иле.

Исерекләр һәм угрылар,
Юләрләр иле...

Башкалар күптән гарьләнеп
Үләрләр иде.

ӨЛГЕРЕРБЕЗ!

Кырын-кырын карыйбыз без
Күптән узган заманнарга.
Ни өчендер яратабыз
Узганнарны яманларга.

Яманлыйбыз үзебезнең
Җанга якын үткәннәрне.
Димәк ки, яшь чагыбызны,
Кочканнарны-үпкәннәрне.

Нинди генә булса да ул –
Үзебезнең гомеребез.
Яшик әле!
Яманларга
Без кайчан да өлгерербез.

...ТОРАМ

Мин барсын да күреп торам,
Барсын да белеп торам.
Мыегым астыннан гына
елмаеп-көлеп торам.
Кайчагында башларымны
Юләргә салып торам.
Башкалар кылган гамәлдән
Гыйбрәтләр алып торам.
Карап торам, тыңлап торам,
Мыекка чорнап торам.
Үзем дә түзеп инде әй –
Дәшмичә чыдап торам.
Барсын да аңлап торам мин,
Барсын да сынап торам...
Дәшмичә күпме түзәрмен,
Дип авыр сулап торам.

БУЛАЛМАДЫМ...

Мин Тукай була алмадым –
Бик яшьли үләлмәдем,
Ватанымны вә халкымны
Даннарга күмәлмәдем...

Мин Тукай була алмадым,
Туфан да булалмадым.
Туфан сөргенгә сөрелгән –
Мин анда булалмадым...

Мин Тукай була алмадым,
Такташ та булалмадым,
Хәтта лауреат билгесен
Таккач та булалмадым...

Мин Тукай була алмадым,
Җәлил дә булалмадым.
Батырлык мәсьәләсендә
Әллә ни кыралмадым.

Белмим, нишләр идем икән
Мин алар урынында...
Роберт Миңнуллин булу да
Бик авыр әле монда.

ШУЛАЙ БУЛЫРГА КИРӘК!

Инде беләм: бу тормышта
Усал булырга кирәк.
Хәтта иң усалларга да
Мисал булырга кирәк.

Тыйнакларга көн юк бездә, –
Әрсез булырга кирәк.
Чукынып китсен дөньясы! –
Гамьсез булырга кирәк.

Мөлаемлык кирәк түгел, –
Кырыс булырга кирәк.
Нечкә күңел белән авыр, –
Корыч булырга кирәк.

Моңлыларга яшәү кыен, –
Моңсыз булырга кирәк.
Тизрәк баеп калыр өчен
Комсыз булырга кирәк.

Бакыр булсаң да, мөнбәрдә
Алтын булырга кирәк.
Безнең халык ышана ул, –
Болтун булырга кирәк.

Кеше төсле яшим дисәң,
Карак булырга кирәк!
Кирәк, ләкин азрак кына
Саграк булырга кирәк!

Гомумән, шәп кешеләрдән
Ерак булырга кирәк.
Иң әйбәте, бу дөньяда
Дурак булырга кирәк!

Ә мин дурак булалмадым...
Бик аңлыйм – бик тә кирәк!
Ләкин дурак булыр өчен
Баш җитми – акыл кимрәк.

ЧҮПЛЕКТӘГЕ ШИГЫРЬЛӘР

Ачу килеп йөри иде
Өйдә чүп-чар күплеккә, –
Бөтенесен чыгардым да
Ташладым мин чүплеккә.

Әмма ләкин мин ташлаган
Чүп-чар белән берраттән
Кайчандыр язып куелган
Шигырьләр дә эләккән.

Мин инде ул шигырьләрне
Яңабаштан язалмам.
Бер тапкыр янган утларда
Кабат-кабат яналмам.

Мин, билгеле, аптырашта,
Белмим нәрсә әйтергә? –
Ул шигырьләрнең берсе дә
Төшми минем хәтергә.

Ярар, алар, юньле булса,
Искә төшәрләр иде...
Укучылар гына менә,
Белмим, нишләрләр инде?



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Винни-Пух – дөньядагы иң беренче топ-блогер. Ул җыен юк-барны сөйләп йөргән, башында гел чүбек булганны да яшермәгән, язганы-сызганы ялгыштан торган, ләкин аны барысы да яраткан һәм тамагын туйдырган.

• • •

Билгесез бирәүдән, залда музыканы яхшы ишетә торган кеше утырганын белгәч, "Евровидение" конкурсына эвакуация ясарга туры килгән.

• • •

– Алё, бу телефон буенча сексмы?

– Юк, безгә секс булды ни, булмады ни...

– Ни мәгънәсендә?

– Картлар йорты мәгънәсендә...

• • •

Кулны гел юа торгач, 1989 елгы шпаргалканы таптым.

• • •

Этләр аптыраашта – бөтен кеше битлектән.

• • •

Әгәр дә сезгә берәрсе әҗәтле икән, өенә барыгыз. Ул хәзер өйдә!

• • •

– Миңа табиб спирт язып бирде!

– Бәлки, спорт?

– Бәлки... аларның язганын кем таный соң?

• • •

– Беләсеңме, син бит минем беренчем.

– Чынлапмы?

– Нольдән башласаң...

• • •

Мәгариф министрлыгы мәктәп мәсьәләләрен чын тормыш белән бәйләмәкче. Мәсәлән, алма мәсьәләләре урынына кредитка түләүне санау тәкъдимен.

• • •

– Сәлам! Кәеф ничек?

– Карлсонныкы кебек – пропеллер әйләнә, ә беркая оча алмыйм...

• • •

Кияүгә чыкканчы яки өйләнгәнче уйлагыз – сезгә бу кеше белән карантинда утырырга туры килмәгәе...



Александр АЛЁШИН

Александр БРЮХАНОВ

Тикшерү

– Карале. Синең акчаң бармы?

– Бернәрсәм дә юк... Шәп-шәрә мин... Хәерче дияргә була...

– Ничек инде, ә шәһәр артындагы коттеджың?

– Ул әбиемнең йорты...

– Ә үзәк урамдагы ике фатир кемнеке?

– Берсе кайнанамныкы, икенчесен туачак улым өчен тотам...

– Банкта мул гына счётың бар иде бугай?

– Әйе, бар, тик анда хәзер ике йөз дә дүрт сум ята...

– Ә яшәвең кайда?

– Элекке хатынымда бер почмак алып торам.

– Ничек түлисең соң?

– Ничектер җаен табам инде... Хезмәт хакы айныкы аена гына җитә.

– Син бит яхшы ала идең...

– Ярлыларга өләшәм... Үземә калмый... Тыйнаклык кешенең күрке бит...

– Алай икән.. Ә мин синнән биш йөз сум алып тормакчы идем.


– Ә сез үзегез кем соң?..

– Мин Хакимиятнең әхлакый кануннарга тәңгәл килүен тикшерү бүлегеннән.

– Ә мин салым инспекциясеннән дип торам. Тикшерүне узганмындыр бит инде?

– Әйе. Тулысынча тәңгәл киләсең...

– Алай булгач, миңа сезгә мең сум. Кайтарып маташмагыз...



Юрий КОНЬКИН

Абау!

КОММУНАЛЬ УКЧЫ

Калининградтагы ТСЖ рәисе берөзлексез шикаять язып теңкәгә тиюче пенсионерны акылга утыртыр өчен киллер яллаган. Аяусыз план турында оперативхезмәткәрләр белеп алганнар. Алар корбан булырга тиешле кешенең фатирында инсценировка ясаганнар. Эшләнгән эштән риза булган управдом киллерга 100 мең сум акча түләгән һәм кулга алынган. Хәзер ТСЖ хезмәткәрләре түләү квитанциясендә яңа җөмлә – киллер хезмәте барлыкка килергә мөмкин дип шаярталар.

ТОТА АЛСАҢ ТОТ

Екатеринбургта элеккеге ДПС взводының командирын кулга алганнар. Ул узган ел хезмәттәшләренең кузенә ришвәт алу белән чалынган була, өч елга шартлы срок ала. Ә күптән түгел ачыкланганча, погонлы убыр полициядә хезмәт иткән вакытта хат ташучыларга һөҗүм итеп акчаларын алган икән. Соңыннан җинаятьчене эзләүдә катнашкан. Эштән киткәннән соң лейтенант криминаль эшен ташламаган. Гомуми алганда ул почтальоннардан 700 мең сум талап алган.

НӘРСӘ БЕЛӘН БАЙ

Карелиянең Питкеранта шәһәрендә аз керемле гаиләләрдәге мәктәп балаларын азык-төлек җыелмалары белән тәэмин итүгә тотынганнар. Тик "мәктәпнең азык-төлек комбинатында" запас күп булмаган, балаларга нәрсә бар шуны өләшкәннәр. Льготалы списоктагы һәрбер балага берәр кило он һәм шикәр комы, 1 пачка май, 7 бәрәңге, 2 сосиска биргәннәр. Бу тугыз көнгә исәпләнгән. Кабынып киткән җәнҗалдан соң коры паекны балаларга тагын бер тапкыр алып киләчәкләр, тик бу юлы яңартылган рәвештә.

ЧҮПТӘН ЮЛ

Ярославль өлкәсендә икътисадый хәлгә карамастан, яңа юл барлыкка килгән. Шопшинский районының администрациясе Лисицыно авылында төзелеш чүбеннән юл җәйдергән. Монда яшәүчеләр мондый бүләккә шатланыргамы, еларгамы икәнен белмиләр. Элек аларның юлыннан машина белән генә үтеп булмаган, ә хәзер ул бетон, пластик кисәкләреннән һәм арматура белән катнаш пыяладан торган юлдан җәяү дә йөреп булмый.



КАРАНТИН ҖИМЕШЛӘРЕ



ВИРУСЛЫ СҮЗЛӘР


• Бөтен дөнья финанс системасының каты авырып китүе өчен бер төчкерүнең җитүе ачыкланды.

• Үзизоляция режимын бозган өчен штраф түләү – ул һава өчен салым түләү кебек – суларга чыккансың икән, түлә!

• Бу коронавирусны хатын-кыз уйлап чыгаргандыр, ахрысы: 1. Ананнан ирләр күбрәк үлә. 2. Спорт матчлары үткәрелми. 3. Бөтен төнге кафелар, күңел ачу урыннары эшләми. 4. Барча исән калганнар өйдә хатыннары белән утырырга мәҗбүр.

• Бу үзизоляция белән халык санының кискен аруы йә аның эчеп үлүе көтә безне.





ЙОГЫШЛЫ ФИКЕРЛӘР

• Бер атна карантинда утырганнан соң, кешеләр этләрнең «Гулять!» командасына ник шатлануларын яхшырак аңлый башладылар.

• Карантиннан да куркынычрак нәрсә – үзизоляциядәге күршеләрнең ремонт ясавы.

• Ә хөкүмәтебез бит урманда чыбык-чабык җыюны һәм җәя белән җәнлек аулауны рөхсәт итеп искиткеч зирәклек күрсәтте.

• Карантин аркасында хатыннарның кашлары табигый хәленә кайтты. Табигать терелеп килә.

• Үзизоляция аркасында бик күп гаиләләр сакланып калды: сөяркәгә тотарга акча булмаганлыктан юлдан язган ирләр хатыннары янына кайта башлады.

• Безнең кешегә бәхетле булу өчен кешечә кибеткә чыгып керү кирәк.

• Коронавирустан иң үтемле чара – көненә өч тапкыр берәр стакан спирт. Дәвалануның икенче атнасында вируслар күзгә күренерлек булып үсәләр, һәм аларны кул белән бәреп үтерергә була.

• Юл инспекторлары аптырауның чигенә җиткән: машиналардан спирт исе аңкый, ә йөртүчеләре аек.





ЮЛСЫЗЛЫК КАЗАНЫШЫ

Кадерле "Чаян"! Без бәяли һәм саклый торган милли казаныш тарихи һәйкәлләр, музей дәлилләре генә түгел... яки Газпром. Мин моңа Алабуга районындагы Иске Мурзиха белән Токмаш авылларына илтә торган юлны да кертер идем. Чөнки әлеге юлны 30 елдан артык җимерелгән килеш һаман саклыйлар!

Әлеге "казаныш"ның озынлыгы – 7 чакрым! Шул еллар дәверендә район вәкилләре әлеге юлны төзекләндерә алмый азапланалар, сәбәбен дә табып кына торалар. Йә баланс туры килми, йә төзекләндерү материалларын кайтарта алмыйлар, йә акчалары юк. Юл шул кадәр кызганыч хәлдә, советлар заманыннан калган асфальтның чокырына барып төшмәс өчен урап узарга туры килә. Бездә юллар начар түгел, бары тик юлсызлык казанышыбыз сыйфаты гына борчый, дип тынычландырырга кала үзебезне.

В. ӘХМӘТОВ

АЛАБУГА


ФАТИРЛАРГА ҖИЛ ХУҖА

Хөрмәтле редакция! "Салават күпере" торак комплексында яшәүче халыкның елданел кәефе төшә бара. Ни өчен дисезме? Әлеге районның кирәкле инфраструктуралары гына булмау җитмәгән, фатирларда да күп җитешсезлекләр ачыла тора.

Ничәмә-ничә кыш фатирларында туңарга туры килә аларга, чөнки йортлар заманча технология белән газобетон плитә һәм җилләндергеч фасадлар белән төзелде. Тик менә төзәтүчеләр генә йортның кирәгеннән артык кибүенә һәм утыруына әзер түгелләр. Фатирларда җил уйный башлады, бүлмәләр салкын һәм нурсыз. Йөзләгән кеше, 7, 8, 10, 11, 12, 13 нче санлы кварталларда торучылар гарантияләнгән төзекләндерү эшләрен таләп итә башлады. Ләкин төзүчеләр йортларны тиз төзесә дә, хаталарын төзәтергә ашыкмый. Хәзер исә һәр яңа кыш халыктан түземлек кенә түгел, саллы чыгым таләп итә башлады. "Акыллы" ягулык, бүлмәләрдә салкын икәнлеген аңлагач, батарейларга өстәмә җылы бирә. Ягулыкка килгән исәп-хисап кәгазе тиздән ипотека бәясен дә узып китеп, бу яңа технологияләр алтын бәясенә әйләнмәсә ярый инде...

"Салават күпере" торак комплексында яшәүчеләр

КАЗАН



Максим СМАГИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА

Алмаз ХӘМЗИН

ҖИҢӘРБЕЗ!

Авыр булды...
Революция ясадык унҗидедә,
Буржуйларны кудык барысын да.
Авыр булды...
Яңа ил төзедек, индустрияләдек,
Сүктек Алласын һәм мулласын да.
Авыр булды...
Фашистларны җиңдек без кырык биштә,
Кырды алар күкрәк баласын да.
Авыр булды...
Берәү килде генсек, икәү, өчәү, дүртәү –
Төзи яздык бит коммунизм да!
Авыр булды...
Таркалды Ыс, Ыс, Ыс, Ыр, калдык без кысыр,
Вак халыклар Ры-СыФы-Сырында.
Таландык кабаттан буржуйдан, карактан,
Олигархлы дәүләт статусында.
Бик, бик авыр, әлбәттә!.. «Ур-ра» курсында –
Җиңәрбез коронавирусын да,
Посып утырсак өйдә, «Чаян»ны укып,
Һәрберебез үз квартирасында!

Владимир ТИХОНОВ



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Бөек остазлар! Нотыкларыгызны сөйләгәндә колакларыгызны томаламагыз!

Иң күп ялган сугыш вакытында, аудан соң һәм сайлаулар алдыннан була.

Тарих бернәрсәгә дә өйрәтми. Ул дәресләрне белмәгән өчен җәза гына бирә.

Җир шары – Галәмнең җүләрләр йорты ул.

Күктән иңгән сүзләр тәгәл һәм аңлаешлы – чөнки алар киңәшчеләр һәм белгечләр ярдәменнән башка язылган.

(Акыл ияләре мәҗлесендә язып алынды)

Леонид СОКОЛОВ

Кеше уйлары

Хөрмәтшин кеше уйларын укый белә иде. Бу сирәк сәләт аңа караңгы подъездда таныш булмаган бер бәндә белән маңгайга-маңгай бәрелешкәннән соң барлыкка килде. Бәрелешү шулкадәр көчле булды ки, Хөрмәтшинны, баш мие селкенеп, хастаханәгә алып киттеләр, ә теге бәндәне турыдан-туры төрмәгә озаттылар, чөнки ул фатирлар басып йөрүче карак булып чыкты.

Хөрмәтшинда уйларны уку сәләте нәкъ шушы хәлдән соң барлыкка килде дә инде. Беренче вакытта бу аеруча кызыклы тоелды. Эшкә килә дә укып утыра. Эчтән генә, билгеле...

Һәркемнең үз уйлары. Мәсәлән, офис-менеджер Роза компьютер белгече Кәбировны үзенә өйләндерергә тели. Тегесе – эштән ничек иртәрәк ычкынырга икән дип башын вата. Экономист Сәмәнев долларларны кайчан алсаң шәбрәк буласын исәпләп утыра... Эш турында уйлаучы бер генә кеше дә юк...

Ә начәлникнең уйларын уку Хөрмәтшин аеруча ярата иде. Ул аның нәрсә теләгәнен алдан ук белеп тора, аларны тәгәл итеп үти, шуның өчен начәлникнең иң яраткан хезмәткәрләре санында йөри иде.

Хөрмәтшин юл инспекторлары белән дә уртак тел табарга өйрәнде. Тегеләр әле авызларын ачарга да өлгермәгән, ә ул инде акча суза.

Йә менә башкалар айлар буе көткән белешмәләр алу. Хөрмәтшин түрәнең чыраена нәрсә язылганын укып ала да, кирәк нәрсәне өстәлгә чыгарып сала. Инглизчә язылган булса, долларлар белән бирә.

Табиб янына барса, шундук аның уенда нәрсә икәнен күреп ала. Мәсәлән, «Мең сум – һәм больничный язып бирәм!»

Хәрмәтшин, әлбәттә, куен кесәсеннән алып бирә...

Өендә дә шулай ук – хатыны уйлап кына ала, ә ул инде кибеткә чаба һәм кирәк нәрсәне алып кайтып бирә. Тёщасының уйларын укый: пинсәне тизрәк китерсеннәр иде инде. Күршесенекен: баш төзәтергә каян йөз таңкә табарга икән... Сантехникныкын инде әйтеп торасы да юк...

Һәм шулай көн саен – уку, уку, уку... Көннәрнең берсендә Хөрмәтшинга кеше уйларын уку туйдырды, йөзәр тапкыр укылган, һаман бер үк нәрсәләр... Һәм берзаман ул укый башлады. Бу юлы инде китаплар. Әйтергә кирәк, күпкә кызыклырак икән!..



Газета-журналларның тиражы бик түбән төшкән чак. Ничәнче еллар икәнен язып тормыйм – беләсез! Бу чатаклыкның сәбәбенә төшенеп микән, бәлки, кабат җанландырып җибәрү максатындамы – Үзәк матбугат оешмасы булдырылды ахрысы... Ләкин шикләнәм... бик ышанып бетмим мин моңа. "Өстән" яудырылган фикерләрне куәтләүгә генә кайтып калды бугай аның эшчәнлеге. Шуңа күрәдер тиражлар артмады, киресенчә, ныграк кимеде. Чөнки басылган мәкаләләрнең эчтәлегендә халык мәнфәгатенә туры килгән, аларны кызыксындырган чаралар, гамәлләр күренмәде, кешеләрнең киләчәккә өмет чаткыларын уятуга тырнак очы хәтле дә ышаныч чагылмады. Кая шушы хәлдә газета, журнал яздырып яту. Адәмнең ашарына юк! Телевизорда гел җырлыйлар, бииләр генә. Яңалыкларда – үтереш, киноларда – ришвәтчелек, заводлар ябылган; басуларда трактор күренми, урам тутырык сукбайлар... Болар турында язарга ярамый – безнең ил андый түгел! Җитәкчеләр әйбәт – менә бит матур темалар!.. Ә халык белә, аны алдап булмый, ничек әйтәләр әле русча: "Соловья баснями не кормят!" – диләрме?

Монысы сүз башым булды. Фикеремне мисал белән беркетәм. Тиражлар түбән төшкән чак дип әйткән идем бит баштарак. Менә шул вакытта безне – редакция хезмәткәрләрен җыеп, ничек тираж мәсьәләсен күтәрергә өйрәтә башладылар. Оешманың моңа җаваплы хезмәткәре – бик матур чибәр кыз Гөлләрә, дип әйтик, үз кабинетында гомере буе журналистикада каләм чарлаган кешеләргә акыл сатарга тотынды. Нишләп мин фәкыйрегез дә шунда? Чөнки журналыбызның баш редакторы Йөзүллин мондый дәресләргә йөрүне түбәнчелеккә санады. Үз урынына мине җибәрде. Һәм дөрес тә... Ниндидер, каяндыр бер белмәгән зат килеп, бу өлкәдә сиңа акыл сатсын әле?..

Ул эшен болай башлый иде. Аяклы тактага беркетелгән зур ватман кәгазьгә яшел маркер белән "Smart" дип яза да, графалар сыза башлый, номерлап. Мин шундук аннан сорыйм:

– Гөлләрә, ни дигән сүз ул "Smart"?

– Ул – план дигәнне аңлата, – ди бу миңа. Йөзендә шундый канәгатьлелек балкый. Мине аңгырага чутлаганын сизәм бит инде.

Янәшәмдә утырган "Сөембикә" журналының баш редакторы касыкка төртеп куя.

– Алмаз абый, тик кенә утыр!

– Сорадым гына бит... – дип акландым мин канәгатьсезлек белдереп. – Гөлләрә, нигә сез аны "план" дип язмадыгыз соң?

Ул җавап бирергә теләмәде микән, әллә соравыма дәлил китерергә әзер түгел идеме? Ярар, карыйк, нишли бу?.. Графаларның башына латин хәрефләре белән сүзләр яза башлады. Тик утыра алмыйм бит. Тагын кысылдым:

– *Карагыз әле, бу сүзләр "башкарылачак бурычлар"* түгелме?

– Әйе, әйе, – ди бу русчалап, татарчасы чамалы булгач.

Бүлмәдәгеләр йөзендә теләктәшлек чаткыларын күрсәм дә, куллары ишарәсендә "тик кенә утыр" дигәнне шәйлим.

Ярар, гел бәйләнеп утырырга ул хәтле җүләр түгел лә мин – тындым. Шул вакыт, бәхетсезлегемә, күзлегем колакчыгының шөрепе идәнгә төшкәнен ишеттем. Ах, бердәнбер күзлек иде, менә хәзер каян табыйм инде мин ул шөрепне? Бигрәк бәләкәй бит. Урындыгымны арткарак этеп, күзем белән ламинат идәнне айкыйм. Кыбырсынганымны барысы да сизә бит инде. Кыштырдавым Гөлләрәгә дә охшамады, ахрысы, әйтеп куйды:

– Комачаулама әле, Алмаз абый! – ди.

Мәйтәм:

– Менә күзлегемнең шөребен югалттым.

– Потом найдешь! – дип, үзенчә – русчалап тынычландырды. Каян белсен инде "соңыннан эзләрсең!" – дигәнне татарча әйтергә.

Барыбер дәреснең ахырына хәтле күз кырыем белән генә булса да идәнгә карап утырдым. Шелтә ясардай гамәл кылмадым. Соңыннан башка редакторлар да эзләшеп карадылар, ләкин шөреп каядыр качкан иде. Ярар, өметсезлек белән кул селтәдем дә, бүлмәгә төшеп киттем. Бер колакчынлы күзлек белән атна буе эшләргә туры килде. Ремонтка барырга берничек тә җай чыкмый җәфаландым.

Беркөнне, кояштай балкып, ишектән Гөлләрә килеп керде.

– Алмаз абый, таптым тегене! – ди.

– Ничек?

– Үрмәләп! – ди.

Карале, миңа шулай татарча әйтергә сүзен дә тапкан бит! Бәгыренә төшкәнмен икән, җаныкаемның!..

Тырышкан табар, ташка кадак кагар! – ди татар халык мәкале. Ә менә тираж мәсьәләсе – идәннән шөреп эзләп табу гына түгел шул!



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 5 (1894) май 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 7.05.2020 ел.
Тираж – 1206 Заказ А-1013

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+



Менә инде өч ел **Эрнест ДЫШАЕВ** арабызда юк. Аның бөтен иҗади тормышы «Чаян» белән бәйле булды. Эрнестның карикатуралары журналда беренче тапкыр ерак 1957 елда басылып чыккан иде. Бу үзенчәлекле үзешчән рәссам вакыт узу белән оригиналь стиль иясе, оста карикатурачыга әверелде. Аның кабатланмас персонажларын укучылар үз итте. Бернинди мактулы исемнәр һәм хөкүмәт бүләкләренә ия булмаган Эрнест Дышаев чын мәгънәсендә халык рәссамы иде.







